**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

№ 13 18.05.2015ел

Аксубай муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрен җирлек башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашырудан тыш, шулай ук автомобиль юлларын куллану һәм юл эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитетына кабул ителгән очракта:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советының 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм карауга тапшыру.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сөнчәле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.В.Крайнова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН" РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ